**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

бишенче утырыш

11 декабрь 2020 ел **№ 26** Теләче авылы

«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгарифен үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыруның барышы турында

«Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» докладын тыңлаганнан соң, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгарифен үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы турында МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» докладын игътибарга алырга.

2.Теләче муниципаль районы башкарма комитеты, район Башкарма комитетының Финанс - бюджет палатасы, МКУ «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» тарафыннан чыгымнарны оптимизацияләү һәм мәгарифкә чыгымнарны нәтиҗәле сарыф итүне арттыру буенча юл картасын әзерләргә.

3.МКУ «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»:

- Теләче муниципаль районы территориясендә база гомуми белем бирү оешмаларының оптималь челтәрен булдыруны тәэмин итәргә;
- мәгариф оешмаларында яшь педагогларны җәлеп итү һәм беркетү буенча чаралар комплексын эшләү өчен тәкъдимнәр эшләргә, максатчан уку кысаларында Теләче муниципаль районыннан студентлар алуга мониторинг ясарга;
- Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүнең персонификацияләнгән системасы турындагы Нигезләмә нигезендә мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүне һәм яңадан әзерләүне оештыруны тәэмин итәргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов